| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.07.2018 Казан шәһәре № под-1161/18

Җитәкче вазифасына кандидатларны Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләрен аттестацияләү турындагы Положениене раслау турында

2012 елның 29 декабрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә белем бирү» федераль законының № 273-ФЗ 51 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы проблемалары» дигән 08.05.2009 № 287 Постановлениесе кысаларында б о е р а м:

1. Җитәкче вазифасына теркәлгән кандидатларга һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләрен аттестацияләү турындагы Положениене расларга (алга таба - Положение).

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 нче елдагы № под-9489/15 «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт учреждениеләре җитәкчеләрен һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучыларны аттестацияләү тәртибе турындагы Положениене раслау» приказын гамәлдәге көчен югалткан дип исәпләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар сәясәте бүлегенә (Н. Б. Алексеева) кул куелган приказны эш көннәре белән

хисапланган өч көн вакыт эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы дәүләт регистрациясенә җибәрергә.

4. Бу приказның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Министр вазыйфаларын башкаручы А. И. Поминов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
30.07.2018 елдагы № под-1161/18
приказы белән

Положение
Җитәкче вазифасына кандидатларга һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләренә аттестация уздыру

1. Гомуми положениеләр

1.1. Җитәкче вазифасына кандидатларны һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләрен аттестация уздыру бу Положение (алга таба - Положение) җитәкче вазифасына кандидатларга һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләрен аттестация уздыру тәртибен һәм аның вакытларын билгели. (Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы бу оешмалар өчен учредитель функцияләрен башкара).

1.2. Белем бирү оешмаларының җитәкчеләре вазифаларына бу Положение Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларның педагогика хезмәткәрләренең, җитәкче хезмәтен башкаручыларның вазифалар номенклатурасын раслау» Постановлениесендә (2013 елның 8 августы №678) «Җитәкче» категориясенә караган вазифалар кертелә.

1.3. Аттестация узарга тиеш:

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкче вазифаларына кандидатлар (алга таба – кандидатлар, Министрлык).

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмаларының җитәкчеләре (алга таба - җитәкчеләр).

1.4. Җитәкчеләр арасыннан аттестация узарга тиеш түгел:

йөкле хатыннар;

балага узганлык һәм бала тудыру белән бәйле ялда булучы хатыннар (аларга ялдан чыгуларына бер елдан да ким булмаган вакыт узгач, аттестация уздырыла);

авыру булу сәбәпле эш урынында рәттән дүрт айдан артык булмаучы җитәкче.

Калган кандидатларга һәм җитәкчеләргә аттестация – мәҗбүри эш..

1.5. Белем бирүче оешма җитәкчесе вазифасына кандидатлар, эш урынына билгеләнгәнче, мәҗбүри рәвештә аттестация узарга тиеш.

1.6. Аттестация җитәкчеләрнең һәм кандидатларның квалификация дәрәҗәләре белем бирүче оешма җитәкчесе вазифасы таләпләренә тәңгәл килү-килмәвен билгели.

1.7. Аттестациянең төп бурычлары булып санала:

җитәкчеләрнең һәм кандидатларның белемнәрен, квалифкацияләрен һәм профессиональ эшчәнлеген объектив бәяләү;

максатчан, өзлексез профессиональ үсешкә һәм шәхси камиллеккә этәреш бирү;

идарә итү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү;

җитәкчеләрнең һәм кандидатларның потенциаль (яшерен) мөмкинлекләрен файдалану перспективаларын ачыклау.

1.8. Аттестациянең төп принциплары – коллегиальлек (эшне бергәләп алып бару), ачыклык, объективлык, дискриминациягә юл куймау.

1.9. Кандидатларга һәм җитәкчеләргә Министрлык төзегән аттестацияләү комиссиясе аттестация уздыра (алга таба - Аттестацияләү комиссиясе).

1.10. Кандидатларны һәм җитәкчеләрне аттестацияләү процедурасын методик, аналитик һәм оештыру-техник яктан Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге тәэмин итә.

## П. Аттестацияләү комиссиясе

2.1. Аттестацияләү комиссиясе җәмәгатьчелек нигезендә эшли.

2.2. Аттестацияләү комиссиясе эшенең төп принциплары булып компетентлык, объективлык, ачыклык, мөстәкыйльлек, профессиональ әхлак кагыйдәләрен саклау тора.

2.3. Аттестациялəү комиссиясе:

кандидатлар (кандидат) һəм белем бирүче оешманың җитəкчесе хакында тəкъдим ителгəн материалларны анализлый, шул исəптəн аларны квалификация белешмəлəрендə күрсəтелгəн, белем бирүче оешма җитəкчесе вазифасына һəм (яки) профессиональ стандарт талəплəренə тəңгəл килү-кимəвен тикшерə, педагогик эшчəнлек белəн шөгыльлəнүгə киртə булмаслык нигезлəрнең, белем бирү сферасында хезмəт итүне чиклəүлəр юклыгын билгели;

кандидатларны һəм җитəкчелəрне һəрьяклап, объектив өйрəнə;

эш нəтиҗəсендə җитəкчелəрнең, кадидатларның квалификация дəрəҗəсе җитəкче вазифасына куелган талəплəргə тəңгəл килү (тəңгəл килмəве) турында

карар кабул итə.

2.4. Аттестациялəү комиссиясе хокуклы:

кандидатлардан (кандидаттан), белем бирүче оешма җитəкчесеннəн, шулай ук тиешле оешмалардан, Министрлыкның профильле бүлеклəреннəн үз эшчəнлеге өчен кирəкле документлар, материаллар һəм мəгълүмат соратып алырга;

соратып алынган документларны, материалларны һəм мəгълүматларны тапшыру вакытын билгелəү;

кирəк булган консультациялəр уздыру;

составы Аттестациялəү комиссиясе раслаган экспертлар, белгечлəрдəн торган эшче төркемнəр оештыру.

2.5. Җитəкче вазифасына кандидатларны һəм җитəкчелəрне аттестациялəү вакытын Министрлык билгели.

2.6. Аттестациялəү комиссиясенең төп эш формасы булып утырышлар санала.

Аттестациялəү комиссиясенең утырышының урыны, датасы һəм вакыты турында аның əгъзаларына хат яки телефонограмма белəн хəбəр ителə.

2.7. Аттестациялəү комиссиясенең составы Министрлык боерыгы белəн раслана.

Аттестациялəү комиссиясенең составына Министрлык, мəгариф һəм фəн хезмəткəрлəренең Татарстан профсоюз оешмасы, Министрлыкның җəмəгатьчелек советы, Министрлык кармагындагы карамагындагы белем бирүче оешмаларның

попечительләр советлары, җәмәгать эшлекләләре, югары белем, иҗтимагый оешмалар вәкилләре.

Аттестацияләү комиссиясенең составы кабул ителәчәк карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр бәрелешенә мөмкинлек калдырмаслык итеп оештырыла.

Аттестацияләү комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасында турыдан-туры яки читләтеп мәгълүм аттестация узучыга шәхси кызыксыну туса, ул утырыш башлану алдыннан моның турында хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта ул аттестацияләнүче турында карар кабул итүдә катнаша алмый.

2.8. Аттестацияләү комиссиясе рәис, аның урынбасарлары, җаваплы секретарь, аттестацияләү комиссиясе әгъзаларыннан тора.

2.9. Аттестацияләү комиссиясенең рәисе Аттестацияләү комиссиясенең эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, утырышларда рәислек итә, Аттестацияләү комиссиясенең эшен оештыра, кабул ителгән карарларның үтәлүен контрольдә тота, Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары арасында вазифаларны бүлә.

2.10. Аттестацияләү комиссиясенең рәисе урынында булмаганда, вазифаларын ул урынбасарларының берсенә тапшыра, һәм ул урынбасар үтәлергә тиешле эшләрне башкара.

2.11. Җаваплы секретарь:

аттестацияләнүчеләр тапшырган аттестацияләнүгә гаризаларны һәм башка документларны эшкәртә;

Аттестацияләү комиссиясенең утырышларына хәзерлек эше алып бара;

Аттестацияләү комиссиясенең әгъзаларына һәм аттестацияләнүче җитәкчеләр һәм кандидатларга утырышның урыны, числосы һәм вакыты турында хәбәр итә;

утырышның көн тәртибен формалаштыра, аттестация документларын гомумиләштерә һәм аларны Аттестацияләү комиссиясенә тапшыра;

Аттестацияләү комиссиясенең утырышларында беркетмә алып бара;

аттестацияләү нәтиҗәләре буенча язылган боерыклардан өземтәләр әзерли һәм шулар белән кандидатларны, директорларны кул куйдырып таныштыра;

Аттестацияләү комиссиясе исеменнән сораулар һәм белдерүләр җибәрә.

2.12. Аттестацияләү комиссиясенең әгъзалары Аттестацияләү комиссиясе утырышларында шәхсән катнашалар.

2.13. Аттестацияләү комиссиясенең утырышы катнашучылар саны составының гомуми саныннан өчтән икесеннән дә кимрәк булмаганда гына хокуклы булып санала.

2.14. Аттестацияләү комиссиясенең карарлары Аттестацияләү комиссиясенең утырышында катнашучы әгъзаларның ачык тавыш бирүе аша ачыкланган тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда,

Аттестацияләү комиссиясенең утырышында рәислек иткән кеше тавыш биргән карар кабул ителгән булып санала. Аттестацияләү комиссиясенең әгъзалары тәкъдиме белән карар яшерен тавыш бирү белән дә кабул ителергә мөмкин.

Рәис, аның урынбасарлары, җаваплы секретарьъ, утырышта катнашкан әгъзалар кул куйган Аттестацияләү комиссиясенең карарлары беркетмәләр итеп формалаштырыла.

Кабул ителгән карар белән килешмәүче Аттестацияләү комиссиясенең әгъзасы язма рәвештә үзенең аерым фикерен белдерергә хокуклы, аның язмасы Аттестацияләү комиссиясенең утырыш беркетмәсенә өстәлә.

Аттестацияләү комиссиясе карары нигезендә Аттестацияләү комиссиясе утырышыннан соң җиде эш көне дәвамында Министрлыкның аттестацияләү нәтиҗәләре турында приказы игълан ителә.

Аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтәләр аттестацияләнүчеләрнең кулларына, кул куйдырып, тапшырыла.

Аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтә җитәкченең шәхси делосында саклана.

Аттестацияләнгән кандидат белән хезмәт килешүе төзегәндә, боерыктан өземтә аның шәхси делосында саклана.

2.15. Аттестацияләү комиссиясе әгъзасы булган аттестацияләнүче җитәкче аттестация узганда үз кандидатурасы буенча тавыш бирүдә катнашмый.

2.16. Положение нигезендә гамәлгә кертелгән җитәкчеләрне һәм кандидатларны

аттестацияләү процедурасын бозу турындагы низаглар Россия Федерациясе законнарына туры китереп карала.

## III. Кандидатларны аттестацияләү тәртибе

3.1. Кандидатны аттестацияләү Положениенең №1 кушымтасы буенча аттестация уздыру турында Аттестацияләү комиссиясенә тапшырылган гариза (алга таба – гариза) нигезендә уздырыла;

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары

(Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының урынбасары), белем бирү оешмасының эшчәнлеген координацияләүче (алга таба – кураторлык итүче министр урынбасары);

кандидат тарафыннан.

3.2. Кандидатны кураторлык итүче министр урынбасары тәкъдим итү очрагында бергә теркәп җибәрелә торган хатта дәлилләнгән, бөтен яклап һәм объектив бәя кандидатның профессиональ стандарт (квалификацион характеристика) «Белем бирүче оешманың җитәкчесе» нигезендә формалашкан эшчәнлегенә, эшкә бәйле сыйфатларына, профессиональ эшчәнлегенең нәтиҗәләренә дәлилләнгән, һәрьяклап һәм объектив бәя булырга тиеш.

3.3. Аттестацияләү гаризасында теркәлә:

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) башка хезмәт эшчәнлеген расдаучы документның күчермәсе;

белеме турындагы документлар күчермәсе;

соңгы өч ел эчендә квалификациясен күтәрү (профессиональ яңадан хәзерләү) турындагы документлар күчермәсе;

аттестацияләү кәгазенең яисә моннан алдагы аттестацияләү нәтиҗәләре турындагы боерык өземтәсенең (булганда) күчермәсе;

китерелгән мәгълүматларны тикшерүгә һәм эшкәртүгә кандидатның ризалыгы турында гаризасы (Положениенең №2 кушымтасы);

хөкемгә тартылу (тартылмау)  һәм (яисә) җинаяткә бәйләнешле эзәрлекләү яисә җинаяткә бәйләнешле эзәрлекләү аклау нигезендә туктатылуы турында белешмә.

3.4. Документларның күчермәләре кандидатның эш бирүчесе имзасы белән раслана. Кандидат вакытлыча эшләмәсә, документларның күчермәләрен Аттестацияләү комиссиясе  секретаре раслый.

3.5. Кандидат документларын тула күләмдә тапшырмаса яки формалаштыру кагыйдәләрен бозса, Аттестацияләү комиссиясе аттестация уздырудан баш тарта.

3.6. Аттестацияләү комиссиясе гаризаны алган көннән 10 эш көне дәвамында гаризага теркәлгән документларга тикшерү оештыра.

3.7. Документларны тикшерү нәтиҗәсендә кандидатка аттестацияләү процедурасын уздыруга ризалык бирелми, әгәр ачыкланса:

педагогика эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә киртә булырлык сәбәпләр, белем бирү сферасында хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә чикләүләр;

хезмәт килешүенең Россия Федерацясе Хезмәт кодексының 51 нче маддәсе буенча өзелүе (күрсәтелгән маддәнең 3, 5, 6, 8, 9, 11 нче пунктлары).

3.8. Аттестацияләүнең теләсә кайсы этабында гамәлдәге квалификация таләпләренә яисә профессиональ стандартка тәңгәп килмәгән, педагогика эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә,  белем бирү сферасында хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә чикләүләр яисә тапшырылган документларда алдау ачылган очракта, кандитатлар Аттестацияләү комиссиясе карары белән  аттестация узмаучылар булып санала.

3.9. Белем бирү оешмасының җитәкчесе вазифаларына кандидатлар (кандидат) һәм  аттестация узарга тиешле җитәкче аттестациянең узу урыны, числосы һәм вакыты турында почта аша яисә телефонограмма белән аттестациягә хәтле 15 эш көненнән дә соңгармыйча кисәтеләләр.

3.10. Кандидат үзе Аттестацияләү комиссиясе утырышында була. Кандидат утырышта үзе булмаса, аның кандидатурасы каралмый.

3.11. Аттестацияләү комиссиясе утырышында катнашу мөмкинлеге булмаса, аттестацияләү графигына кирәкле үзгәрешләр кертелә.

3.12. Аттестацияләү комиссиясе утырышында кандидат үзе булмаса яки ул белем бирү оешмасының җитәкче вазифасына яраклы түгел дип танылса, ул аттестацияне кабаттан аттестацияләү комиссиясе утырышы көненнән ике елдан да ким булмаган вакытта уза ала.

3.13. Аттестацияләү комиссиясе ... ? тәкъдим ителгән докусентларны, кандидат белән әңгәмә оештыра һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

белем бирү оешмасының җитәкче вазифасына лаек;

белем бирү оешмасының җитәкче вазифасына тәкъдимнәрне исәпкә алганда лаек;

белем бирү оешмасының җитәкчесе вазифасына лаек түгел.

3.14. Кандидатны аттестацияләү нәтиҗәләре бер ел дәвамында көчендә кала.

3.15. Аттестацияләү комиссиясе карары белән белем бирү оешмасының җитәкче вазифаларына яраклы түгел дип табылган кандидатлар карар кабул ителүгә ике ел үткәч кенә аттестацияне кабаттан уза алалар.

## IV. Җитәкчеләргә аттестация уздыру тәртибе

4.1. Белем бирүче оешмаларның җитәкчеләренә карата чираттагы һәм чираттан тыш аттестация узу каралган.

4.2. Җитәкчегә чираттан тыш аттестация Министрлыкның карары белән түбәндәге сәбәпләр булганда уздырыла:

документлар белән дәлилләнгән берничә тапкыр җитәкче тарафыннан федеральъ һәм республика законнарын бозу;

документлар белән дәлилләнгән белем бирү оаешмасында белем алучылар тарафыннан укыту программаларын үзләштерү хәрәкәтенең алдагы чор белән чагыштырганда тискәре якка үзгәрүе;

белем бирү оешмасының эш нәтиҗәләренең түбән күрсәткечләренә дәлилләнгән, дөрес булып чыккан белем алучыларның (аларның вәкилләренең) шикаятъләре;

белем бирү оешмасы җитәкчесенең шәхси карары.

4.3. Белем бирү оешмасының җитәкчесенә чираттан тыш аттестация уздыру турында карар министрның кураторлык итүче урынбасарының чираттан тыш

аттестация уздыруның сәбәбе күрсәтелгән эш кәгазе яисә Аттестацияләү комиссиясенә кергән белем бирү оешмасы җитәкчесенең гаризасы нигезендә кабул ителә.

4.4. Кураторлык итүче министр урынбасарының эш кәгазе нигезендә чираттан тыш аттестациягә җибәрелгән җитәкче Аттестацияләү комиссиясенә (Положениегә №1 кушымта) гаризасын үзенә карата чираттан тыш аттестация оештыру турында карар чыкканнан соң биш эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

4.5. Чираттан тыш аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестацияләү нәтиҗәләренең гамәлдә калу вакыты яңартыла. Элекке нәтиҗәләрнең гамәлдә булуы тукталыла.

4.6. Җитәкченең чираттагы аттестациясе шулай ук җитәкченең Аттестацияләү комиссиясенә биргән гаризасы (Положениегә №1 кушымта) нигезендә уздырыла:

хезмәт килешүенең вакыты үткәнче биш айдан да элек һәм ике айдан да соңга калмыйча – беренче тапкыр чираттагы аттестация узучы җитәкчеләргә;

элек билгеләнгән нәтиҗәләрнең гамәлдә калу вакытына биш айдан да элек һәм ике айдан да соңга калмыйча – шул ук уку йортында чираттагы аттестацияне узган җитәкчеләр өчен.

4.7. Аттестацияләү гаризасына документлар күчермәсе өстәлә:

белеме һәм аттестацияләнү узу алдыннан өч ел эчендә алынган өстәмә профессиональ белеме турындагы документлар күчермәсе;

алдагы аттестация нәтиҗәләре турындагы боерыктан өземтә (булган очракта).

4.8. Аттестацияләү комиссиясенә чираттагы аттестацияне узу турындагы гаризаны үз вакытында тапшыру өчен аттестацияләнүче белем бирүче оешмасының җитәкчесе җавап бирә.

4.9. Белем бирүче оешманың җитәкчесе гаризаны тапшырмаса яисә бу Положениенең 4.6 пунктында билгеләнгән ике айдан соңрак вакытта тапшырса,

Аттестацияләү комиссиясе җитәкче адресына гаризаны тапшыру вакытын үтәмәүгә аңлатма сорап хат җибәрә һәм бу факт турында кураторлык итүче министр

урынбасарына һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрына хәбәр итә.

4.10. Белем бирүче оешманың җитәкчесе игътибарга лаеклы булмаган сәбәп аркасында Аттестацияләү комиссиясенә гаризаны үз вакытында бирмәгән өчен, хезмәт законнарына туры китереп, дисциплинар җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

4.11. Аттестацияләү комиссиясе гаризаны алуга биш эш көне дәвамында

оештыру турындагы мәгълүматны министрның кураторлык итүче урынбасарына җибәрә, ул, үз чиратында, әзерлек эшләрен һәм Аттестацияләү комиссиясенә аттестацияләнүче җитәкчегә Положениенең №3 кушымтасында күрсәтелгән форма буенча таныклама (алга таба - таныклама) җибәрә.

4.12.Таныкламага җитәкченең аттестацияләүгә хәтле ике уку елы дәвамында Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 25.06.2013 елдагы № 2441/13 боерыгында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеген бәяләү критерийларын раслау» китерелгән критерийларны үтәве турында мәгълүматлы аналитик белешмә өстәлгән булырга тиеш.

4.13. Аттестацияләү процедурасының дәвамлыгы гаризаны алган көннән Аттестацияләү комиссиясе карар кабул иткәнче 45 календарь көннән артмаска тиеш.

4.14. Аттестацияләү комиссиясенә килгән таныклама белән белем бирү оешмасы

җитәкчесен җаваплы секретарь, кул куйдырып, аттестация уздыруга 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, таныштыра.

4.15. Таныклама белән танышкач, белем бирү оешмасының җитәкчесе Аттестацияләү комиссиясенә үзенең өч ел дәвамындагы эшчәнлеген

сыйфатлаган мәгълүматлар бирә ала, шулай ук таныкламада рәсми җитәкчесе китергән мәгълүматлар белән килешмәсә, тиешле дәлилләр китереп гариза язарга

хокукы бар.

4.16. Белем бирү оешмасының җитәкчесе таныклама белән танышудан баш тартса, тиешле акт төзелә.

4.17. Аттестацияләү комиссиясе утырышында аттестацияләнүче җитәкче үзе булырга тиеш.

4.18. Игътибарга лаеклы сәбәпләр аркасында (авыру булу, командировка һ.б.)

җитәкченең аттестацияләү комиссиясе утырышында була алмау очрагында аттестацияләү графигына тиешле үзгәрешләр кертелә.

4.19. Игътибарга лаеклы булмаган сәбәпләр аркасында Аттестацияләү комиссиясенең утырышына килмәгән җитәкчене комиссия аттестацияләүне аннан башка уздырырга хокуклы.

4.20. Аттестацияләү комиссиясе утырышы алдыннан җитәкче Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларына аттестацияләү процедурасын уздыруга бәйле өстәмә мәгълүматлар булу-булмавы турында хәбәр итә,

4.21. Аттестацияләү комиссиясе таныкламада китерелгән аттестацияләнүче турындагы мәгълүматларны, таныклама белән килешмәү очрагында аның дәлилле гаризасын җентекләп карый, шулай ук аның «Белем бирү оешмасының җитәкчесе» дигән профессиональ стандартка (квалификацияүон характеристика) тәңгәл килү-килмәвенә бәя бирә.

4.22. Аттестацияләү комиссиясе әгъзаларының кирәк очракта аттестацияләнүчегә үзенең вазифаларын үтәү белән бәйле сораулар бирергә хакы бар.

4.23. Аттестацияләү комиссиясе әгъзалары уздырылган эш нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итәләр:

белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифаларына туры килә;

белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифаларына, тәкъдимнәрне исәпкә алганда, туры килә;

белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифаларына туры килми.

4.24. Җитәкчеләрне аттестацияләү өч елга бер тапкыр уздырыла. Җитәкчеләрнең вазифаларына туры килүен раслау максаты белән аттестацияләү хезмәт урынына билгеләгәннән соң ел дәвамында уздырыла.

4.25. Белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифаларына туры килми дигән карар кабул ителгән җитәкченең гаризасы нигезендә Аттестацияләү комиссиясенең

кабаттан аттестацияләү уздыру турында карар кабул итәргә хокукы бар. Аттестацияләү уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында белем бирү оешмасының җитәкчесенә шушы Положениегә туры китереп хәбәр ителә.

4.26. Үзенә карата кабаттан аттестацияләү турында карар кабул ителгән җитәкче Министрлык приказы белән аттестацияләүне уңышлы үткәнче кирәк вакытка эшеннән алына, җитәкче вазифаларын башкару урынбасарарларының берсенә йөкләнә.

4.27. Аттестацияләү комиссиясе үзенә карата белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифаларына туры килми дигән карар кабул ителгән җитәкче, хезмәт турындагы законнарга туры китереп. эшеннән алына (чыгарыла).

Кушымта № 1
җитәкче вазифасына кандидатларны
һәм Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән миистрлыгы карамагындагы
белем бирү дәүләт оешмаларының
җитәкчеләрен аттестацияләүне уздыру
турындагы Положениегә
(аттестацияләү комиссиясенең исеме) дән
(фамилиясе, исеме, ата исеме)вазифасына
кандидат (яки вазифасына билгеләнгән)
хезмәт урынының һәм учреждениенең исеме

ГАРИЗА

Минем документларымны каравыгызны һәм мине квалификация характеристикасына тәңгәл килү-килмәвемне билгеләү максатыннан аттестацияләвегезне үтенәм

хезмәт урынының һәм оешманың исеме

Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны белдерәм:

Туган ел, число, ай

Белем (кайчан нинди белем бирү учреждениесен тәмамлаган, алган белгечлеге һәм квалификациясе

Өстәмә профессиональ белем (яки квалификацияне күтәрү курслары) дәүләт яки муниципаль идарә, менеджмент һәм экономика юнәлешләрендә

Гомуми эш стажы , шул исәптән педагог эше стажы ел, җитәкче эше стажы ел, аттестацияләнәсе вазифада ел.

Бу учреждениедә елдан эшлим (яки эшләмим).

Хезмәт кенәгәзеннән өземтә өстим (җитәкче вазифасына кандидатлар өчен)

Шундый наградалар, дәрәҗәле исем, фәнни дәрәҗә, фәнни званиеләрем бар.

ИКТ- технологияләр белән эш итү дәрәҗәсе (югары, канәгатьләнерлек, түбән) (кирәклесенең астына сызарга)

Түбәндәге документларны өстим: (санап чыгу).

Хезмзт урынына бәйле квалификация характеристикасы таләпләре белән һәм җитәкче вазифасына кандидатларны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән

министрлыгы карамагындагы белем бирүче дәүләт оешмалары җитәкчеләрен аттестацияләүне уздыру турындагы положение белән таныштырылдым.

«_______»___________________ 20_____ел.                Имза

Кесә телефоны                                        Эш телефоны

Кушымта № 2
җитәкче вазифасына кандидатларны
һәм Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән мииистрлыгы карамагындагы
белем бирү дәүләт оешмаларының
җитәкчеләрен аттестацияләүне уздыру
турындагы  Положениегә
(аттестацияләү комиссиясенең исеме) дән
(фамилиясе, исеме, ата исеме)вазифасына
кандидат (яки вазифасына  билгеләнгән)
хезмәт урынының һәм учреждениенең исеме

**Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә җитәкче**

**вазифасына кандидатның ризалыгы**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирү дәүләт оешмасының исеме
Мин,________________________________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме)

адрес буенча теркәлгән

паспорт серия ________№ ______,

бирелгән_____________________________________________________________

_____________________________________________________________________

ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз ихтыяҗымда Татарстан Респуликсы мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләрне һәм кандидатларны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы белем бирү дәүләт оешмалары җитәкчеләре вазифаларына аттестацияләүне уздыру комиссиясенә автоматлаштыру чараларын яисә андый чараларны файдаланмыйча (теләсә кайсы гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасы, җыю, язып алу, систематизацияләү, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), өземтә ясау, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, файдалануга рөхсәт, блокировка, алып ташлау, юкка чыгару) кулланып, түбәндәге персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалашам: фамилия, исе ата исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлык, ээлеккеге фамилия, исем, ата исеме, аларны үзгәртү датасы, урыны һәм сәбәбе (үзгәртү очрагында); хезмәт эшчәнлеге башыннан башкарган эш (берьюлы ике урында эшләүне дә кертеп, эшкуар һәм башка эшчәнлек), хәрби хезмәт, дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр, орденнар һәм медальләр (кем бүләкләгән һәм кайчан), туган җир, эш урыны, яшәү урыны буенча регистрацияләү адреслары (тору урыны), паспорт, (серия, номер, кайчан һәм кем биргән), шулай ук хезмәт эшчәнлегенә караган башка персональ мәгълүматлар.

Югарыда күрсәтелгән персональ мәгълүматларны Татарстан Республикасы мәгариф һәи фән министрлыгы карамагындагы белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифасына кандидат буларак мәҗбүри  аттестацияләү узу максатыннан эшкәртүгә бирәм.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык язуны имзалаган көннән гамәлгә керүе белән таныш. Мин китергән мәгълүматларның дөреслегенә җаваплылык турында кисәтелдем.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны ирекле формада язылган гариза нигезендә кире кайтарырга мөмкин.

« ____» ________________20 ___ел.                    ______________________

имза

Кушымта № 3
җитәкче вазифасына кандидатларны
һәм Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән миииструлыгы карамагындагы
белем бирү дәүләт оешмаларының
җитәкчеләрен аттестацияләүне уздыру
турындагы Положениегә
(аттестацияләү комиссиясенең исеме) дән
(фамилиясе, исеме, ата исеме)вазифасына
кандидат (яки вазифасына билгеләнгән)
хезмәт урынының һәм учреждениенең исеме

ТАНЫКЛАМА

белем бирү оешмасының исемен күрсәтеп, вазифа, тулы фамилия,. исем, ата исеме җитәкче вазифасына тәңгәл килү-килмәүне ачыклау максатыннан аттестацияләнү өчен

1. Гомуми мәгълүматлар

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Туу датасы (число, ай, ел) | |
| 2. | Белем турында мәгълүматлар (югары, кайсы<br>профессиональ белем бирү учреждениесен тәмамлаган, тәмамлау датасы | |
| 3. | Диплом буенча белгечлек | |
| 4. | Диплом буенча квалификация | |
| 5. | «Дәүләт һәм муниципаль идарә», «Менедмент», «Персонал белән идарә итү» юнәлешләре буенча әзерлек белеме | |
| 5.1. | Хәзерләүнең юнәлеше | |
| 5.2. | Уку йортының исеме | |
| 5.3. | Укуның озынлыгы | |
| 5.4. | Укуны тәмамлау датасы | |
| 6. | Идарә итү эшчәнлеге профиле буенча | |

| | | |
|---|---|---|
| | өстәмә белем | |
| 6.1. | Исеме | |
| 6.2. | Белем бирү  учреждениесенең исеме | |
| 6.3. | Уку сәгатьләренең саны | |
| 6.4. | Тәмамлау елы | |
| 7. | Гомуми эш стажы (ел) | |
| 8. | Педагогик эшчәнлек  стажы (ел) | |
| 9. | Бу вазифада эшләү  стажы (ел) | |
| 10. | Бу учреждениедә  эшләү стажы (ел) | |
| 11. | Аттестацияләнәсе вазифага билгеләнү датасы | |

П. Профессиональ эшчәнлектә төп уңышлар

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. | Педагогик эшчәнлек буенча квалификация категориясе (исеме, аны бирү турындагы приказның датасы) | |
| 2.2. | Орден, медальләрнең булуы (исеме, елы) | |
| 2.3. | Гыйльми дәрәҗәнең булуы (исеме, елы) | |

2.4. Профессиональ, эшкә бәйле сыйфатларын, профессиональ стандарт (квалификацион характеристика) «Белем бирү оешмасының җитәкчесе» нигезендә формалашкан профессиональ җитәкче эшчәнлегенең нәтиҗәләренә дәлилләнгән, җентекле һәм объектив бәя бирү (аттестацияара вакытында)

2.5. Тәкъдимнәр белән нәтиҗә ________________________________________

________________________________________________________________________

(үтәлергә тиешле вазифага тәңгәл килү/килмәвен тану мөмкинлеге турында мәгълүмат)

2.6. Кушымта – бу җитәкченең аттестацияләүгә хәтле ике уку елы дәвамында Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 25.06.2013 елдагы № 2441/13 боерыгында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеген бәяләү критерийларын раслау» китерелгән критерийларны үтәве турында мәгълүматлы аналитик белешмә.

«__»_______ 20____ел.

Татарстан республикасы
Мәгариф һәм фән министрының
Беренче урынбасары ___________ _________________

имза имзаны ачыклау

Таныклама белән таныштырылдым, риза, «__»_______ 20____ел.

___________________________ ___________ _________________

(Белем бирү оаешмасы җитәкчесенең вазифасы) имза имзаны ачыклау

Таныклама белән таныштырылдым, риза түгел, «__»_______ 20____ел.

_____________________________ ______________ _________________

(Белем бирү оаешмасы җитәкчесенең вазифасы) имза имзаны ачыклау